ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасында авыл территорияләрен комплекслы үстерү турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасында авыл территорияләрен комплекслы үстерү турындагы мәгълүматын тыңлап һәм аның буенча фикер алышып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының авыл территорияләрен комплекслы үстерү турындагы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына авыл халкы тормышының җитешлеген һәм аны эш белән тәэмин итү дәрәҗәсен арттыруга, уңайлы яшәү шартларын булдыруга, мәгариф һәм сәламәтлек саклау юнәлешләре буенча социаль хезмәт күрсәтүләрдән һәркем файдалана алырлык шартларны булдыруга, шулай ук юл инфраструктурасының сыйфатын арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруны дәвам итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Татарстан Республикасы авыл территорияләрен үстерү мәсьәләләрен җайга сала торган норматив хокукый актларга анализ ясарга һәм өстәмә хокукый җайга салу кирәклеге ачыкланганда тиешле норматив хокукый актлар кабул итүне тәэмин итүне.

3.2. Төп торак пунктларны һәм аларның янәшәсендәге территорияләрне – Татарстан Республикасы авыл агломерацияләрен социаль-икътисадый үстерүнең озак сроклы планнарын әзерләү, килештерү һәм раслау эшен дәвам итүне.

3.3. Авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру мәсьәләләре буенча семинарлар һәм «түгәрәк өстәлләр», «Авыл яши – Деревня живет» пилот проектын гамәлгә ашыруны да кертеп, уздыруны оештыруны.

4. 2024 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты, Татарстан Республикасында авыл территорияләрен комплекслы үстерү өлкәсендә өстәмә законнар белән җайга салу кирәклеге ачыкланганда, закон актлары проектларын аларны алга таба билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертү өчен әзерләүне башкарырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2314-VI ДС